СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №35 (7208) | 25 март, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Сафларыбыз ишәя

«Мине КПСС членлыгына кабул итүне үтенәм, чөнки коммунистлар сафында булырга телим. Мин халкыбызның тормыш хәлен яхшыртуга бар тырышлыгын куйган бүтән партия булмавына ышанам...»

Бу юлларны мин «Алга» колхозыннан Р. М. Сафинның гаризасыннан китердем. Бүген ил һәм КПСС тормышында катлаулы чор кичергәндә мондый гариза язу һәркемнән югары аңлылык, тирән үзгәрешләрне сизәрлек гуманлылык һәм зирәклелек таләп итә.

Шундый катлаулы чорда КПСС сафларына килүчеләр арасында олы тормыш юлы узган, коммунистик идеяләргә инанган төрле буын вәкилләре бар. Гомерен балалар тәрбияләүгә, партия идеяләрен пропагандалауга багышлаган педагог Таһир Шәймәрданович Гобәйдуллин («Рассвет» совхозы), Петр Игнатьевич Ефимов (Мичурин исемендәге колхоз) һәм башкалар олы гомер сукмагы узган кешеләр. «Заветы Ильича» колхозыннан Евгений Геннадьевич Тришин, XXI партсъезд исемендәге колхоздан Равил Җәмилович Нуруллин исә тормыш юлына яңа аяк басучылар.

КПСС сафларына керүчеләр өчен 21 мартта истәлекле вакыйга булды. Партия сафларына керүче 16 иптәшкә КПСС райкомы бюросы членнары катнашында таныклыклар тапшырылды. Партия билетларын КПСС райкомының беренче секретаре, партиянең республика комитеты члены Х.Х. Морадыймов тапшырды. Ул яшь коммунистларны тормышларында истәлекле вакыйга белән кайнар тәбрикләде, җәмгыять тормышында актив эшчәнлеккә чакырды.

Агымдагы ел барышында КПСС сафларына 21 яңа член кабул ителде. Башлангыч партия оешмаларына үзләрен КПСС сафына кабул итүне сорап язган гаризалар тагын да керә.

В. ХОМЕНКО,
КПСС райкомының партия учеты секторы мөдире.

Людмила Ивановна Михеева Норлат шикәр заводында 1968 елдан бирле эшли. Ул еллар эчендә планкалар бирү эшчесе, фильтрлаучы, аппаратчы ярдәмчесе булды һәм 1973 елдан рафинад утфеле пешерү аппаратчысы дигән төп, җаваплы һөнәрне үзләштерде. Табигате буенча да игътибарлы, җаваплы Людмила Ивановна хәзер менә дигән шикәр пешерү остасы булып җитеште. Үзенең намуслы хезмәте өчен күп тапкырлар Мактау грамоталары белән бүләкләнде.

Тагы бер горурлыгы бар Людмила Ивановнаның: үзенең туган заводына улы Сергейны да тарта алды ул. Бу булдыклы һәм тырыш егет ТЭЦта дежур инженер булып эшли, читтән торып Димитровград техникумын тәмамлый. Киләчәктә анардан да әнисе кебек үк һөнәренә тугры, җаваплы эшче чыгасына шик юк.

Рәсемдә: аппаратчы Л.И. Михеева.

Кышлату ничек бара?

Фермаларда киеренке чор

Колхоз-совхозларда малларлар кышлатуның иң җаваплы этабы бара. Хәлиткеч этапта кемнәр ничек эшли соң?

Моны ачыклау өчен башта кайбер әйбәт хуҗалыкларның савучылары эшенә күз салыйк. «Большевик» колхозы савучылары бүгенге көндә үзләренә беркетелгән һәр сыердан тәүлеккә уртача 10,5 килограмм сөт савып алалар. Көнлек савым беренче март белән чагыштырганда 900 граммга арттырылган. Шундый ук күренешне «Заря» колхозында да күрергә мөмкин. Биредә һәр сыерга тәүлеклек савым 10,4 килограмм тәшкил итә.

«Үрнәк» колхозы савымчыларының да уртача тәүлеклек савымы һәр сыерга 10,4 килограммга җитте. Шунысы куанычлы, алар март башы белән чагыштырганда һәр сыерга тәүлеклек савымны 1 килограмм 400 граммга арттырганнар. Әйбәт күрсәткеч белән эшләүче хуҗалыклар арасында «Рассвет» совхозын да күрергә мөмкин.

Савымның әйбәт булуына бу хуҗалыклар терлекчеләре малларны чиста, көр тотулары, даими рәвештә санитар көннәр үткәрүләре белән ирешкәннәр. Аларда малларга азык эшкәртелеп бирелә, рационны басту турында да күп уйланыла. Сыерлар физиологик үзенчәлекләре буенча группаларга тупланган, шуңа карата ашату да тиешенчә оештырыла. Терлекчеләр арасында 5 көн саен йомгак ясала, уңышлар һәм җитешсезлекләр билгеләп үтелә.

Ә менә «Алга», Кузнецов исемендәге, Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, «Москва» һәм башка кайбер колхозларда сөт һаман да артмый әле. Атап үткән хуҗалыкларның савымнары иң югарысында да тәүлеккә һәр сыерга 6 килограммнан артмый.

Мондый колхоз-совхозларда терлекчеләр арасында хезмәт дисциплинасы йомшак. Терлекчеләрнең һәм хуҗалык белгечләренең эшкә бармак аша каравы нәтиҗәсендә сөт продукциясен арттыру турында уйларга да мөмкин түгел. Хуҗалыкларда кулланыла торган зооветеринария таләпләре үтәлмәү бик аяныч нәтиҗәләргә китерә. Рацион туклыклылык буенча балансланмый,анда каротин җитешми, азык эшкәртелми, савымга нәтиҗәләр ясалмый. Мондый җитешсезлекләрне күпләп санарга мөмкин.

Һәм шулар нәтиҗәсендә район буенча алына торган савым да түбән. Үткән елның бу чоры белән чагыштырганда районда һәр сыердан тәүлеклек савым 600 граммга түбән әле.

Савымнары түбән хуҗалыклар уйлашырга, җитешсезлекләрне кимчекмәстән бетерергә, язгы—тагын да авыр чорда, продукция җитештерүне арттыра бару өчен бөтен мөмкинлекләрен эшкә җигәргә тиешләр.

Язгы пычракларда малларның продуктлылыгын киметмәү өчен азыкларны тик эшкәртеп кенә ашатырга, терлекләрнең асларын чиста, биналарны коры тотарга кирәк. Бер үк вакытта савым сыерларын прогулкага чыгаруны да онытырга ярамый. Барлык ветеринария таләпләрен үтәүдә бу кыен чорда продукт алуны киметмәскә булышыр.

Х. ФӘТХУЛЛИН,
авыл хуҗалыгы идарәсенең баш зоотехнигы.

Актуаль мәсьәлә тикшерелде

Норлат агач складында булып үткән партия җыелышында коммунист А.В. Барановның үзенә йөкләтелгән эш участогында эшчәнлеге турында отчеты тыңланды. Отчетны тикшерү барышында, склад эшендәге уңай моментлар белән беррәттән, тәнкыйть фикерләре дә шактый ишетелде. Хуҗалыкның мөһим цехы саналган бу участокта кешеләр җитешмәү, запас частьләр булмавы соңгы нәтиҗәләргә тискәре йогынты ясый. Эстакаданы яңадан үзгәртеп кору зарури.

Җыелышта сүз алучылар кибет эшен дә тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәяләделәр: кискен дефицит чорында күп промышленность товарлары эшчеләргә сатылмый, читкә китә. Кибет эшчәнлегенә агач складының администрациясе һәм эшче контроль җитәрлек түгел.

Җыеп әйткәндә, коммунистлар җыелышта актуаль мәсьәләләр турында принципиаль сүз алып бардылар. Җыелыш барышында Антонина Ильинична Никифоровага «КПСС сафларында—50 ел» билгесе, урман хуҗалыгы администрациясе һәм партия комитетының кыйммәтле бүләге тапшырылды. Тантана барышында партия һәм хезмәт ветераны адресына күп җылы сүзләр әйтелде. Һәм ул боларга лаек та.

Е. АЛЕКСАНДРОВА,
Октябрь урман хуҗалыгы партия комитеты секретаре.

Бүгенге санда

*ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ
*ЫНДЫРДА ЫҢГЫРАШМАС ӨЧЕН
*ПАТРИОТ
*АВЫЛ, СИНЕ НИЧЕК ТЕРЕЛТЕРГӘ?
*СЫЙФАТ—ЭШТӘ ТӨП ЭТӘРГЕЧ

Язның бер көне—ел туйдыра

Арендачылар язга хәзерләнә

Безнең «Кондырча» колхозында игенчелек белән шөгыльләнү өчен ике аренда звеносы төзелгән иде. Үткән елдагы әйбәт нәтиҗәләр аларга яңа көч бирде. Шуңа күрә яңа уңыш өчен көрәшкә хәзерлеккә дә ныклап тотындылар. Миңняр Бакиров һәм Сәлих Гомәров җитәкләгән бу звенолар ремонт эшләренең бөтен төрен дә үзләре башкарып чыкты. Һәр ике звеноның әгъзалары Фәрит Абдуллин, Мансур Вәлиев, Идрис Хөсәенов, Хафиз Халитов һәм башкалар чәчкечләрне, тырмаларны, культиваторларны ремонтлап бетерделәр. Аларның бу эштә беренче ярдәмчеләре, киңәшчеләре булып колхозның унган токаре —Фәнис Гатауллин, эретеп ябыштыручы Насыйх Ибәтуллин, тимерче Хатыйп Халитов зур тырышлык күрсәтте.

Ике арендада да тракторлар саны бертигез. Бу тракторларны көйләү җайлауда арендачылар үзләре эшләделәр, шул ук вакытта комбайннарны ремонтлау эше алып барылды.

Тагылма җайланмалар 25 мартта комплектланып бетте. Тракторларны да эшләтеп, төп узелларын тагын бер кат күздән кичергәч, 5 апрельдә колхозның белгечләре, тәҗрибәле механизаторларыннан торган комиссия аларга бәя, язгы кыр эшләрендә уңыш теләп фатиха бирәчәк.

Булсын дип эшләүче бу унганнар ремонтта да, чәчүдә дә сынатмаска тиешләр.

Х. РӘХМӘТУЛЛИН.

Кырда сынатмас өчен

Яз тулысы белән үз көченә кереп бара. Көннән көн аның җылы сулышы сизелә. Болай да юка булган кар катламы басуларда каралырга, юкарырга кереште, юлларда, иңкүлекләрдә сулар җыела башлады.

Язның көне—ел туйдыра, ди халык. Моны истән чыгарырга ярамый. Әнә шуңа күрә авыр һәм җиңел тырмаларны ремонтлауда эшләүче Александр Лаврентьев, Николай Рассадин, Виктор Кузьмин эшкә аеруча җаваплылык белән карыйлар. Алар бүгенге көнгә колхоздагы барлык тырмаларны да тулысынча ремонтлап куйдылар инде. Культиваторлар һәм чәчкечләрне ремонтлау өчен җаваплы Иван Артамонов, Михаил Черепановлар да үз эшләрен җиренә җиткереп башкаралар.

Колхозыбыздагы 21 тракторның унтугызы бүгенге көндә басуга хәзер чыгып китәрлек булып көйләп, җайлап куелды. Биредә беренчеләрдән булып үз техникаларын әзерлек сызыгына куйган механизаторлардан Борис Шувалов, Сергей Ермишкин, Александр Никифоровлар булды. Хәзер тракторлар сынау үтәләр, төп механизмнарны җайлаулар бара, кабат күздән кичерү һич тә зыян итмәгәнлеген беләләр тракторчылар. Чәчү башлангач, вакытны сарыф итмичә, нәкъ менә файдалы хезмәткә генә тоту, кыр эшләренең һәркайсын үз срогында башкарып чыгу гына уңышның нигезен тәшкил итәчәк бит. Үткән елгы авыр табигать шартларында мул уңыш өчен көрәштә тупланган тәҗрибәләре, осталыклары механизаторларга быел да ярдәм итәр диясе килә.

В. МЕЛЬНИКОВ.

Синдряков исемендәге колхоз.

ПАТРИОТ

Махсус чыгарылыш № 2 (143)

Егетләр хәзерлек уза

Һәр совет гражданины Ватанын сакларга әзер торырга тиеш. Мәктәптә бу юнәлештә эш башлангыч хәрби хәзерлек укытучысы җитәкчелегендә алып барыла. Моның өчен программада дәресләр каралган, хәрби эш кабинеты җиһазландырылган. Аларда яшь буынны туган илгә бирелгән итеп тәрбияләү буенча байтак чаралар күрелә.

Патриотик тәрбиягә класстан тыш чараларда да даими игътибар бирелә. Хәрби хәзерлек физик чыныгудан аерылгысыз, шуңа күрә укучылар дәрестән тыш вакытларда спорт секцияләрендә чыныгу узалар. ГТО нормаларын тапшыру өчен көзен һәм язын төрле ярышлар үткәрелә. Совет Армиясе һәм Хәрби-Диңгез Флоты көне алдыннан мәктәптә план нигезендә оборона-масса эше айлыгы үткәрелә. Аның барышында быел да класс җитәкчеләре Коралды Көчләр үткән данлы юл, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы чорында совет халкының каһарманлыгы, герой якташларыбыз һәм башкалар турында укучылар белән әңгәмәләр үткәрделәр. Классларда патриотик темага багышлап стена газеталары чыгарылды, рәсемнәр конкурсы оештырылды, әдәби фильмнар демонстрацияләнде. Педагоглар, пионервожатый җитәкчелегендә 6—7 класслар арасында «Аҗаган» уены оештырылды. Пневматик мылтыктан ату буенча «Яшь мәргән» ярышлары финалына [illegible] команда чыкты. Призлы урыннары XI, X, VIII класс командалары яуладылар. «Яшь мәргән» билгесенә Валерий Васин, Николай Горшков, Вячеслав Дмитриев, Иван Журавлев, Алексей Захаров, Владимир Мизонов, Илдар Хөсәенов, Сергей Яллин лаек булдылар.

Айлык ГТО нормасы тапшыру буенча чаңгы ярышлары белән тәмамланды. Әмма егетләрне алда байтак яңа чаралар көтә әле. Алар арасында Бөек Ватан сугышында җиңүнең 46 еллыгына хәзерлек буенча чаралар иң алгы планда.

А. ГРЕЧУШНИКОВ.
Төрнәс урта мәктәбе.

ГВАРДИЯ РЯДОВОЕ

ТӘБӘНӘК, чандыр гәүдәле, яңакларында җыерчыклар ярылып яткан Иван Семенович, сигезенче дистәгә күптән аяк баскан булса да, җитез һәм хәрәкәтчән. Гомер буе балта, көрәк белән эш иткәнгә симерүдән тыны кысып интектерми аны.

Балта дигәннән, анысы гомер буена кулыннан төшми Иван Семеновичның. Сугыш елларыннан, саперлыктан башлап.

Фронтка сапер булып китүенең тарихы болай аның. Чираты җитеп хәрби хезмәткә китү өчен каралырга баргач, 1936 елда аны армиягә алмыйлар, икенче категория запаска чыгаралар. Бу—строй хезмәтенә яраксыз дигән сүз.

Әмма ил иминлегенә куркыныч янаган моментта, Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан ул хәрби хезмәткә чакырыла. Сәламәтлеген исәпкә алып, аны икенче дәрәҗәдәге участокка—сапер частена җибәрәләр. Дәһшәтле 22 июнь таңын ул хәрби ант кабул иткән солдат булып каршылый.

Сапер һөнәре хәрбиләр өчен икенчел дәрәҗәдә саналса да, сугышның авырлыкларын алгы сызыктагыдан һич ким татымый Веринин. Ул хезмәт иткән 51 нче гвардияче саперлар батальоны гаскәрләр кичү өчен күперләр төзи. Ә күпер ул фронтның һәрчак кайнар ноктасы: дошман сугыш кирәк-яракларын, өстәмә җанлы көч һәм техника кертүне тоткарлау өчен бар көчен куп карыша. Дошман самолетлары саперлар эшләгән кичү өстендә өзлексез тора, бомба коя, пулеметтан кургашын яңгыры яудыра. Алгы сызыктагы пехота мондый көчле һөҗүм вакытында окоп, траншеясы төбенә сыена, яшеренә. Саперларның исә андый мөмкинлеге юк, чөнки зениткалар атып торуга, югалтуларга карамастан, күпер өстеннән дошман очучылары китмиләр дә диярлек: яшеренеп тора калсаң, эшләргә вакыт та тими. Ә алда, фронт линиясендә күпер өлгерүне, ярдәмне безнең сугышчылар көтә. Шуны белеп торганга, гвардияче саперлар дошман уты астында да эштән туктап тормыйлар, сугышчан бурычларын үтәүне дәвам итәләр. Берәрсе яралана, үлә икән, аның урынына алмашка икенче иптәше баса. Минут саен үлем яныса да, балтасын кулыннан төшерми солдат. Веринин да шулай: тыйнак һәм сабыр солдат кургашын яңгыры астында да үз эшен белә.

Сугыш үзенекен эшләп өлгергән: анда алган контузиясе ишетүен йомшарткан. Картлыгы сәбәпле дә бу сәләте кимегән, Иван Семенович белән сөйләшүе кыен, ул бик начар ишетә, үткәннәре турында авырлык белән генә сөйли. Үзе катнашкан хәрби эпизодларны да хәтерләми инде. Куркак солдатлардан булмаган ул үзе, югыйсә, каһарманлыгын тасвирлаучы бүләкләре дә шактый. 1944 елда «Батырлык өчен» медале, III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Сугыш тәмамланган елны исә бу орденның II дәрәҗәсенә дә лаек була.

Веринин хезмәт иткән батальон төрле фронтлар составында сугышчан операцияләрдә катнаша. Балтыйк буендагы канкойгыч бәрелешләр ветеранның хәтеренә аеруча уелган.

—Дошман көчле ныгытмалар артына кереп урнашкан, кискен каршылык күрсәтә иде,—дип искә ала ул сугышның соңгы этабын.—Ә безгә дошман утыннан сыенып урын да юк, окоп казый башлауга су бәреп чыга.

Шундый катлаулы шартларда көрәшәләр совет сугышчылары. Гитлерчыларның котырынып сугышуы, контрһөҗүмнәре аларга булган нәфрәтне тагын да көчәйтә, гайрәтләрен арттыра. Алар бер максат, тизрәк сугышның азагын якынайту хисе белән яналар.

Аның өчен сугыш чынлап та вакытыннан алдарак тәгәлләнә. Безнең гаскәрләр Кенигсбергны азат иткәндә, Балтыйк буенда туплар гөрелтесе тынып калганда Берлин юнәлешендә хәлиткеч бәрелешләр башланмаган да була әле.

Иван Семенович өчен гадилек хас. Фронтта чагында да, яше буенча башкалардан күп олы булса да, үзен күрсәтергә, берәр ягы белән аерылырга тырышмый. Тыйнак сапер туган авылы Богдашкинога әйләнеп кайткач, гап-гади кеше булып кала. Колхозда нинди хезмәткә кушсалар да һич каршы килә, бәхәсләшә белми, төгәл итеп үти. Мактанмый да, зарланмый да. Тормышында әгәр теләсә, моңа урын, нигез күп булыр иде, югыйсә. Герой дәрәҗәсенә тиңләшә язган бу батыр солдат авырлыклар килсә, фронттагыча, күңеленә сеңдерә, кыенлыклар алдында бил бөгә белми. Ә соңгылары тыныч тормышта да тынгы бирмиләр аңа.

Шулай килеп чыга ки, тормыш иптәше Ирина Ивановна вакытыннан алда үлеп китә. Гомерлек юлдашын югалту, үлемне көн саен күреп, иптәшләрен гел югалтып торган солдат өчен дә бик кыен була, йөзендәге сырлары тирәнәя, күңелен олы сагыш биләп ала картның.

Бу аның башына төшкән хәсрәтнең башы гына була әле. Озак та үтми улы Николай, ә аннары килене Раиса да дөнья куя. Иван Семенович өч оныгы: Марина, Алеша һәм Валя белән торып кала. Өч яшь бала белән, аларның иң өлкәне дә нибары өченче класста укый, өлкән яшьтәге картка гомер кичерү мәшәкатьләрен аңлатып тору кирәкме икән?! Веринин, кара кайгысын басып, оныклары өчен яши башлый. Һәм ким-хур итми аларны. Балалар да аның сүзен игътибарга алалар, ата-ана җылысы тоймасалар да, тәртипле һәм тәүфыйклы булып үсәләр. Марина хәзер үзе мөстәкыйль гаилә корды инде. Алексей да күптән буй җиткән егет, колхозда эшли. 5 яшендә калган Валя буй җитеп килә инде. Мәктәптән кайтуга өй эчендәге эшләрне үтәүгә алына.

Веринин үзенең бүгенге тормышына күнеккән инде, оныкларын мөстәкыйль гомер сукмагына чыгарып җибәрә алуына сөенеп көн итә. Әмма тормышның үз кануннары бар бит: күп авырлыклар кичергән карт солдатның сәламәтлеге борчып алгалый. Ләкин Иван Семеновичның аларга бирешер исәбе юк: яу кырында һәм авылда ут-суларны күп кичкән, катлаулы тормыш юлын мактауга лаек итеп үткән гвардия рядовое бит ул Веринин.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

...Танк „тоттылар"

Черкасск өлкәсе Каменск районы ВЛКСМның 30 еллыгы исемендәге колхоз механизаторлары искә дә керүе мөмкин булмаган «байлык» сөйрәп чыгардылар. Алар Телепино авылы буасыннан... «Валентайн» тибындагы инглиз танкысын электерделәр.

Икенче бөтендөнья сугышы вакытында бу типтагы танклар Бөекбританиянең бронетанк гаскәрләрендә төп өлешен тәшкил итәләр иде. Бөек Ватан сугышының авыр көннәрендә инглизләр, союзниклык бурычын үтәп «Валентайннарны» СССР коралды көчләре составына бирделәр. Өлкәннәрнең әйтүенә караганда шушындый танкларның берсе, Корсунь-Шевченко операциясе вакытында,авыл янындагы сулыкларның берсенә эләккән. Шулай итеп танк 46 ел су төбендә ята, ләмгә бик нык күмелә. Көчле алты трактор үзләренең куркыныч туганнарын су төбеннән тартып чыгардылар. Танк яхшы сакланган, кораллары һәм сугыш кирәк-яраклары тәртиптә, урыны белән бронядагы буяулар да купмаган.

«Советская торговля» газетасыннан.

„Солдат хәтере"

Матбугатта басылган сугыш истәлекләре турында сүз чыкса, без, иң элек, генералларыбызның мемуарларын гына күз алдына китерә идек. Ә гади солдат кая соң әле? Аның истәлекләре юктыр, дип уйлыйсызмыни? Ул бит сугышның барлык авырлыкларын үз җилкәсендә күтәргән.

Татарстан китап нәшрияты бу яктан бик изге эш эшләде. Кызыл Байрак орденлы 201 нче Гатчина укчы дивизиясе составындагы 92 нче Сестрорецк гади солдат Әбрар Юныс укчы полкы сугышчысы— улы Юнысов истәлекләрен бастырып чыгарды.

Бөек Ватан сугышы елъязмасыннан

Рәсемдә: партизаннар кър госпиталендә. М. Трахман фотосы. Н. Акимов репродукциясе.

Ветеран зары

Бу хакта сөзгә 75 яшьлек карт, Бөек Ватан сугышы ветераны яза. Мин 1990 елның апрелендә кайтып, Чулпан авыл Советына учетка баскан идем. Сугыш ветераннары өчен билгеләнгән паекны ала килдем. Әмма февраль аенда аны бирмәделәр. Авыл Советына мөрәҗәгать иткән идем, ярдәм күрсәтелмәде. Бәлки сезнең ярдәмегез тияр?...

К. СӨНГАТУЛЛИН.
Чулпан авылы.

РЕДАКЦИЯДӘН: Чулпан авыл Советы работниклары бу юлларны укыгач ветеран зарына колак салыр бәлки?!

Слет үткәрелсә иде

Мин 5 бала тәрбияләп үстергән ана. Аларның өчесе ир-егетләр. Ике улым Совет Армиясе сафларында хезмәт срогын үтеп кайтты. Декабрь аенда төпчегебезне озаттык. Хәзер илдә тынгысыз замана, аналар балаларының язмышы өчен борчыла. Шуңа күрә районда солдат аналары очрашуы (слеты) уздырылса иде. Анда сөйлисе, киңәшәсе, хәл итәсе мәсьәләләр шактый җыела, югыйсә.

Хәзер күп урыннарда чит республика, мәмләкәтләрдә түгел, солдат хезмәтен үзләрендә үтү турында карар кабул иттеләр. Без дә балаларыбызның Татарстанда солдат хезмәте узуын тәэмин итүне сорарга хаклы саныйм. Ил иминлеген сакларга солдат озату мәҗлесенә кирәкле продуктларны табуы бик кыен проблема—шул хакта киңәшәсе, чарасын күрәсе иде. Солдаттан кайтучыларга кием таба алмыйсың—без ни эшләргә тиеш?

Аналар күңелен борчыган тагын бер нәрсә: тиешле хәзерлеге булмаган балаларны милициягә ярдәмгә патрульгә чыгару аларның гомерен куркыныч астына куймыймени?! Без бит аларны исән-имин кайтыр өчен җибәрдек.

Солдат аналары очрашуы оештырылса, без шулар һәм башкалар хакында уртага салып сөйләр, киңәшер, конкрет тәкъдимнәр кертер идек. Минемчә, актуаль проблема бу.

Н. МӨСЛИХОВА,
Заречный поселогы.

Гомерләрен фермада үткәрделәр. Асия Миннаповна Мифтахова һәм Гөлсем Габдрахмановна Сәлахова. Аларның берсе 31, икенчесе 18 ел эшли инде савучы булып. Әйтергә кирәк, исемнәре гел алдынгылар рәтендә аларның. Асия Миннаповнага тырыш хезмәтләре өчен «Татарстанның атказанган терлекчесе» исеме бирелгән иде. Ул бу бөек исемне удар эш белән аклый.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы савучылары А.М. Мифтахова һәм Г. Г. Сәлахова.

Сөтнең сыйфаты ник түбән?

Агымдагы елның өч аенда товарлыклы-сөтчелек фермаларының эш нәтиҗәләреннән күренгәнчә, терлекләрне кышлату шактый кыен шартларда үтә. Яхшы сыйфатлы азык малларга бик аз бирелә, ә начар сыйфатлы азык эшкәртелмәгән килеш ашатыла. Нәтиҗәдә беренче кварталның 2 аенда сөт сату планы район буенча бары тик 53 процентка гына үтәлде. «Алга», Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, «Правда» колхозларында бу күрсәткеч тагын да түбән: ул 34—36 процентны тәшкил итә.

Базар экономикасына күчкән чорда һәм яңа сатып алу бәяләре кертелгәндә авыл хуҗалыгы продукциясенә дәүләтнең дифференциацияле өстәмә түләвен гамәлдән чыгарды. Әмма аның каравы колхоз-совхозлар, аренда коллективлары һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләре, оешмаларында азык-төлек налогы һәм дәүләт заказыннан тыш җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе хәзерләү контораларына һәм башка кулланучыларга ки..шү бәяләре белән сатыла.

Районыбызда сөтнең товарлылыгы да бары тик 78 процентны гына тәшкил итә. «Путь к коммунизму» (56 процент), «Таң» (70 процент), «Москва» (71 процент) колхозлары, «Төрнәс» совхозы (72) бу өлкәдә иң артта сөйрәлүчеләрдән. Ә бит бүгенге бәяләр вакытында хуҗалыклар бары тик югары сыйфатлы продукцияне сатып кына күп акчага ия була алалар. Мәсәлән, «Үрнәк», «Путь к коммунизму», Хафизов исемендәге колхозлар сөтнең сыйфатлылыгы өчен 3285—6450 шәр сум өстәмә табыш алдылар. Тик мондый хуҗалыклар бик аз. Кузнецов исемендәге колхоздан 43, «Төрнәс» совхозыннан 62, Мичурин исемендәге колхоздан 43, Муса Җәлил исемендәге колхоздан бары тик 67 процент кына беренче сортлы сөт саттылар. Бу елның 58 көненә «Төрнәс» совхозы 7385 сум, Кузнецов исемендәге колхоз 2283 сум, Мичурин исемендәге колхоз 2432, «Алга» колхозы 4199, «Игенче» 6284 сум, Муса Җәлил исемендәге колхоз 1539 сум акча югалтты.

Агымдагы елның беренче январеннан 10 градуска кадәр суытылган беренче сортлы сөтнең бер тоннасына 15 сум күләмендә бәя артты. Кайбер фермаларда сөт суыткычлары булуга карамастан, тиешле температурасына җиткереп суытылмый. Шулай, мәсәлән, «Правда» колхозының хуҗасызлыгы аркасында, ул беренче сортлы сөтнең 47 процентын гына суыткан. Нәтиҗәдә 657 сум акчаны алып бетерми. Шулай ук Муса Җәлил исемендәге колхоз 657 сум, Кузнецов исемендәге колхоз 871 сум, «Төрнәс» совхозы 1045 сум акча югалтты.

Әчелеге югары булган сөт сатучы колхозлар да бар. Мәсәлән, шул сәбәпле Ульянов исемендәге колхозга 1152 сумлык, «Алга»га 1408 сумлык, «Сөлчә» совхозына 768 сумлык сөт кире кайтарылды.

Еш кына сөт комбинатка майлылыгы гына түгел, хәтта авырлыгы да үлчәнмичә килә. «Знамя Октября», «Үрнәк», Мичурин исемендәге, «Кондырча» колхозлары шундыйлар рәтенә керәләр.

Алдагы мәгълүматларның аяныч булуына карамастан, аталган колхоз һәм совхоз фермалары белгечләре бу хәлдән чыгуга бөтен көчләрен куялар дип әйтеп булмый. Менә беренче квартал тәмамланып килүгә карамастан, «Правда», «Россия», «Путь к коммунизму», Муса Җәлил исемендәге, «Родина», «Знамя Октября», «Чишмә», «Москва», Кузнецов исемендәге, колхозлар, «Төрнәс» совхозы икенче сортлы сөт тапшыруны дәвам итәләр.

А. БЕЛЯКОВА,
авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча дәүләт инспекторы.

Җиңел яшәп булмый

Авылым минем белән бергә картая. Ә аның киләчәге өчен чын күңелдән борчылам. Дөрес, бүгенге көндә бу мәсьәләгә җитди игътибар бирелә, күпчелек дискуссияләр дә шул хакта. Уйланырга туры килде: мин, үземнең өч дистә елымны шул авыл хезмәтенә багышлаган кеше, аның өчен нәрсә кылдым яки нинди файда китердем? Баксаң, җиргә хезмәт итүдән кала берни дә эшләмәгәнмен икән. План өчен генә тырышып, башканы күрмәгәнмен икән. Урындагы түрә кушуы буенча дәшми-тынмый, . карышмыйча эшләргә күнеккән булып чыктым. Шул принциптан бер генә дә читкә тайпылмадык. Үз өстенлегенне күрсәтеп кара, авызыңны тиз капларлар. Баксаң, шул үткән еллар эчендә уйлау сәләтеннән дә мәхрүм кала язганмын икән.

Миннән беркайчан да үз фикеремне сорамадылар һәм аның белән берәү дә кызыксынмас та иде.

Бүген өлкән яшьтәге тәҗрибәле механизатор авылда иң кыйммәтле кадрлардан санала. Лаеклы ялга китүчеләргә алмашка яшьләр килсә дә, бик тиз үзләшеп китә алмыйлар әле. Алар, беренче чиратта, уңай эш шартлары һәм күп хезмәт хакын таләп итеп куялар. Ә бит мин тракторда эшли башлаганда «Төрнәс» совхозында хәзерге шикелле бөтен уңайлыклары тудырылган үзәк мастерской да, җылы гараж да юк иде. Кичен эштән кайткач, хезмәт урынында эләктергән суыктан билләр язылмый, дегет-мазуттан арынмаган кул бармаклары кәкрәеп ката. Кая инде ул безнең заман эшчеләренә эштән соң калып душта коену? Бу хакта хәтта хыялланырга да булмады. Карагыз әле сез бүгенге яшь механизаторларга, кызыл почмакка кереп теләсәләр телевизор карыйлар, шахмат-шашка уйныйлар, газета-журнал укыйлар. Бәхетлеләр алар. Бер караганда һәммәсе дә үзебездән тора, зарланырга урын юк, тырышып хезмәт куясы иде. Шулай булгач, нәрсә комачаулык итә? Һаман да шул үзебездәге өстенлекне сизмәү инде. Ә без әлегәчә үзебезне җиребезнең чын хуҗасы итеп сизмибез, уңышны арттыру өлкәсендә каяндыр кергән яңалыкларны көтеп ятабыз. Яңалык үзеннән үзе генә керми, моны һәркем яхшы аңлый. Тәҗрибә, күпсанлы уйланулар, кат-кат эзләнүләр нигезендә туа ул. Менә безнең «Төрнәс» совхозы район хуҗалыклары арасында алдынгылардан саналмый. Безнең җитәкчеләр совхозның үсеп китә алмавының төп сәбәбен юл булмауда күрәләр. Һәм бу өлешчә дөрес тә. Авылда гомер буе яшәп, намуслы һәм тырыш хезмәт куйсам да, әле дә булса такыр юлдан йөри алганым юк. Язгы чорда укучы балалар мәктәпкә көймә белән баралар, көзен тракторлар авыл уртасындагы юлдан да үтә алмыйлар. Балчык изә-изә «бил»дән төшеп чума алар. Соңгы елларда мин СК-5 комбайнын иярлим, юлсызлык безнең эш процессына да шактый тискәре йогынты ясый. Машиналарның ындыр табагына ашлык илтеп әйләнеп килгәнен көтә-көтә күп вакыт бушка уза. Юлсызлык кына түгел, башка проблемалар да җитәрлек бездә. Катлаулы дефицит һәм экономика аеруча нык аксаган заманда яшибез бит. Әйтик, механизаторлар запас частьләр булмаудан интегәләр һәм аны хәл итүнең төрле юлларын эзлиләр. Кайчакларда кирәкле детальләрне станокта кырып токарьга яңабаштан ясарга туры килә. Эш вакытында искергән, өзелгән комбайн каешларын адым саен ялгау сәбәпле, тагын күпме вакыт үтә. Ә бит ашлык өчен көрәштә темпны киметмәскә кирәклеген һәркем яхшы белә. Җир законнарын буш сүзләр белән генә исбатлап булмый, бик тирән мәгънәгә ия ул. Тузан эчендә иртә таңнан төн уртасына хәтле комбайн штурвалы тоткан кеше кем булуына карамастан, хөрмәткә, мактауга лаек. Төрле фикердәгеләр очрый: «Тагын нәрсә кирәк, шуның өчен кесә тутырып акчасын алалар», имеш. Акчадамыни хикмәт. Бүгенге көндә, бигрәк тә акчаның бәясе төшеп барганда. Басуда барлык комбайнчылар да үз мөмкинлекләреннән чыгып хезмәт куялар, берәүнең дә начар эшлисе килми. Ләкин кул бармаклары тигез булмаган шикелле, биредә дә тигезлек сакланмый. Берәүгә һәм бары тик берәүгә генә өстенлек бирелә. Аны күккә чөеп мактап башкаларны онытырга ярамый. Алмашка килүче яшьләрнең күңелләре суынмасын. Алар өчен аерым экипажлар оештырырга кирәк.

Үзебез иккән икмәкне Төрнәс пекарнясындагы оста кул пешерүчеләрнең шундый да йомшак, тәмле итеп пешерүләрен күргәч күңел сөенә. Табыныбызның иң түренә куела торган икмәкне авылыбыздагы һәр гаилә көтеп ала, безгә рәхмәт укый. Газеталардан кайбер өлкәләрдә икмәккә булган чикләүне укып, йөрәк әрни. «Талон системасы гына кертә күрмәсеннәр инде» дип борчылалар авылымның өлкән яшьтәге кешеләре. Ходайга шөкер, безнең районда эшчеләр икмәк өчен озын-озын чиратларда тормыйлар, аннан икмәк белән тәэмин итүдә өзеклекләр дә килеп чыкканы юк.

Гади һөнәр иясе булсам да, политика, экономика мәсьәләләре, дөнья вакыйгалары, планета яңалыклары белән кызыксынып барам.

Н. ЧЕРЕВОВ.
«Төрнәс» совхозы.

Японияның авыл хуҗалыгы: авыр юл...

Японияның бер генә промышленность тармагы да, экономика сферасы да, авыл хуҗалыгы кебек, зур кыенлыклар белән очрашмыйдыр. «Пасифик Френд» журналы япон авыллар халкы алдында тау кадәр проблемалар торуын игълан итә.

Авыл халкының картая баруы бүгенге япон авылларының үсешен тоткарлаучы күренеш. Японияның Авыл хуҗалыгы, урманчылык һәм балыкчылык министрлыгының күптән түгел биргән статистика мәгълүматлары илдәге күпчелек авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерге вакытта 55—65 яшьлек кешеләр җитештерүен күрсәтә. Күп кенә крестьян гаиләләрендә төп проблема—балаларның әти-әниләре эшен дәвам иттерергә теләмәүләре. Яшьләр хезмәт хакы дәүләт яки кампанияләр тарафыннан гарантияләнгән, хезмәт нәтиҗәсе һава шартларына һәм базарга бәйле булмаган шәһәрләргә күпләп киттеләр.

Японияның авыл хуҗалыгы, берничә ел элек, дәүләт дөгегә сатып алу бәяләрен һәм күләмен кискен киметкән чорда, аксый башлый. Икенчедән, Япония фермерлары, илнең авыл хуҗалыгы базарын либераллаштыруны һәм авыл хуҗалыгы продукциясен күбрәк чит илгә чыгаруны таләп иткән АКШ һәм Көнбатыш Европа илләренең басымын үзләрендә сизделәр. Элек Япония үзен азык-төлек белән тәэмин итү өчен тукланy продуктларын чит илләргә чыгармаган. Табигый, Япония фермерларының продукциясенә бәяләр төшкән, өстәвенә, илдә икмәкнең дәрәҗәсе артуга бәйле рәвештә, соңгы елларда халык дөге куллануны өчтән бер тапкырга киметкән.

Шушы кризистан чыгу өчен Япония крестьяннары үзенә күрә «саклану» чараларын эзлиләр, гомумән алганда ул коллективлаштыруны хәтергә төшерә. Авыл җирләрендә ирекле крестьян хуҗалыклары союзлары оештырыла. Алар бердәм капитал туплыйлар, бергәләшеп техника һәм ашламалар сатып алалар, тегермәннәр һәм складлар төзиләр, җир эшкәрткәндә һәм уңышны җыеп алганда союзның көчсез членнарына ярдәм итәләр.

«Пасифик Френд» илнең авыл хуҗалыгының киләчәге Япония фермерлары үзләренең хезмәтләрен ничек итеп техник яктан җиһазлауларына һәм җәмәгатьчелек мәнфәгатьләренә ярау өчен үзләренең шәхси масаюларын җиңә белүләренә бәйле, дип күрсәтә.

Рәсемнәрдә: япон фермере гаиләсе тормышыннан фрагментлар, 4 кешелек бу гаилә 2,5 гектар дөге, 1,4 гектар бодай җирен эшкәртә, кыяр үстерү өчен теплицасы бар, 4 үгез симертә.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

СИШӘМБЕ
26 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.15 Мультфильм.
18.25 Ничек яшисең, гимназия?
19.00 Татарстан.
19.30 Документаль телефильм премьерасы: «Синең җырларыңны һәм хикәятләреңне хәтерлим мин».
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 «Редакциягә хат килде». Телевизион журнал.
20.55 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 Актуаль репортаж.
9.15 Балалар сәгате.
10.15 Документаль фильм премьерасы: «Качаклар».
10.40 Дж. Верди. «Фальстаф». Лондонның Ковент Гарден король операсы спектакле.
12.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
12.15 «Фальстаф» операсының дәвамы.
15.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 2 нче фильм, 2 нче серия.
16.25 Музыкаль хәзинәләр.
17.10 Документаль фильм: «Тирә-юнеңә бак һәм исеңә төшер».
17.45 Балаларның музыка клубы.
18.30 Меридиан.
18.45 Хәрәкәт иминлеге.
19.15 Өлкәннәр өчен мультфильмнар.
19.25 «Базарга барабыз». 2 нче тапшыру.
20.10 Нәфис фильм: «Чит кеше алтыны» 1 серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВиД» күрсәтә: «Могҗизалар кыры».
22.30 «Киләчәгебез хакында...» Мәдәни мирас турында.
23.35 Телескоп.
00.50 Телевизион яңалыклар хезмәте.
01.10 Иоһан Штраус исемендәге Вена камера оркестры концерты.
02.10 Нәфис телефильм: «Степанчиково авылы һәм анда яшәүчеләр». 1 серия.
02.55 Шагыйрьләр ярышы.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильмнар.
8.45 Француз теле. 1 уку елы.
9.15 Документаль фильмнар.
9.45 Француз теле. 2 уку елы.
10.15 «Мистер Урал-91» (Уфа).
10.55 Балалар өчен кыска метражлы нәфис фильм «Дүртенче әти».
11.30 Ритмлы гимнастика.
12.00 Балалар өчен фильм: «Гарбузинлыда могҗизалар».
13.20 Документаль фильм премьерасы. «Музыка дәресләре».
13.40 Нәфис телефильм: «Кышкы томаннар вакыты», 1 серия.
21.45 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
23.45 Нәфис телефильм: «Кышкы томаннар вакыты». 2 серия.

ЧӘРШӘМБЕ
27 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.10 Татарстан.
18.40 Телевизион документаль фильм премьерасы: «Моң». Татар композиторы С. Сәйдәшев турында (М).
20.00 «Әлли-бәлли-бәү,
20.10 «Сәхнә утлары». Халыкара театр көненә багышланган тапшыру.
21.05 Мәдхия. (7 март тапшыруын кабатлау).
21.40 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 «Иртә».
9.00 Эшлекле курьер.
9.15 Безнең белән эшлә, безнең кебек эшлә, бездән яхшырак эшлә.
10.15 Документаль фильм премьерасы: «Язмышыңны атлап чык, чегән».
10.45 Халык көйләре.
11.00 Документаль фильм: «Мейерхольд».
12.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 2 нче фильм. 3 серия.
16.35 Һәвәсләр дөньясы.
16.50 «Балалар сәгате» (инглиз теле дәресе белән).
17.50 Останкино концерт студиясендә Ташкент шәһәренең 1 нче югары һөнәр училищесы директоры Тимур Инагамов белән очрашу.
18.50 Н. Пейко. Квинтет-вариацияләр.
19.05 Үзгәртеп кору. Ул Япониядә ничек булды? 3 нче тапшыру.
19.50 Променад концерт күрсәтә.
20.10 Нәфис фильм: «Чит кеше алтыны». 2 серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 Мин сезгә мәхәббәт турында сөйлим...
22.50 Кинопанорама.
01.40 «Степанчиково авылы һәм анда яшәүчеләр». 2 серия.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильмнар.
8.45 Немец теле. 1 уку елы.
9.15 Фильм-концерт: «Җыр белән сихерләнү».
9.45 Немец теле. 2 уку елы.
10.15 Балалар өчен фильм: «Лопотухинга ышансаң». 1 һәм 2 серияләр.
12.20 «Ә безнең театрда нәрсә?». Фильм-күзәтү.
13.45 Нәфис телефильм: «Кышкы томаннар вакыты», 2 серия.
17.00 Нәфис телефильм: «Кигәвен», 2 серия.
21.45 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
23.45 Футбол. Иптәшләрчә очрашу. Германия—СССР җыелма командалары.

ПӘНҖЕШӘМБЕ
28 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.30 Яшьләр өчен телевизион журнал: «Телесеанс».
19.00 Татарстан.
19.30 Төзелеш: проблемалар һәм эзләнүләр».
20.00 Тыныч йокы, нәниләр.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.25 «Шәһәр язы». Зеленодольск район хезмәтчәннәре һәм үзешчән сәнгатьтә катнашучылар белән очрашу.
21.40 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 МВД хәбәрләре буенча.
9.15 Балалар өчен кыска метражлы нәфис фильмнар.
10.25 Футбол. Иптәшләрчә очрашу. Германия—СССР җыелма командалары.
12.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 3 нче фильм. 1 серия.
16.30 Һәвәсләр дөньясы.
16.45 Чемпионнар белән бергәләп.
17.15 Җиңүчеләр.
18.15 Владимир Миарелли җырлый (Италия).
18.30 Меридиан.
18.45 Мультфильм премьерасы: «Том Сойерның гаҗәеп маҗаралары».
19.25 ...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк.
20.10 Нәфис фильм: «Чит кеше алтыны», 3 серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 МВД хәбәрләре буенча.
22.00 Эфирда музыка.
00.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
00.20 «Музыкаль композиция» тыңлагыз.
01.45 Нәфис телефильм: «Бай һәм ярлы». 1 серия.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильм.
8.35 Испан теле. 1 уку елы.
9.05 Документаль фильм: «Коридор».
9.25 Испан теле. 2 уку елы.
9.55 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездын ачу.
12.00 Балалар өчен фильм: «Манараны сакла».
13.00 «Синең чыгыш, артист». Любовь һәм Виктор Анисимовлар.
13.30 Ритмлы гимнастика.
14.00 «Җырны исеңдә калдыр». Балалар һәм зурлар өчен тапшыру.
14.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
17.00 Нәфис телефильм: «Кигәвен». 3 серия.
18.05 Мультфильм: «Җылы ипи».
23.45 Нәфис телефильм: «13 нче Апостолның эзләре».

ҖОМГА
29 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

16.45 Бергәләп өйрәник.
17.10 Нәфис фильм: «Этиләр». 1 серия.
18.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
18.25 «Сыйфат кытлыгы». «Мебель нигә сыйфатсыз?»
19.00 Татарстан.
19.25 «Диалог» турында диалог. Совет-Америка «Диалог» предприятиесенең төзелүе һәм үсеше (Чаллы шәһәре).
20.05 Әлли-бәлли-бәү.
20.15 «Җомга көн кич белән» алманахы.
20.55 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 Инновация. Маркетинг. Нәтиҗә.
9.15 Мультфильм: «Том Сойерның гаҗәеп маҗаралары».
9.55 ...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк.
10.40 Халык хорлары, җыр һәм бию ансамбльләре Бөтенсоюз фестиваленең йомгаклау концерты.
11.40 Документаль фильм.
12.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Нәфис телефильм: «Михайло Ломоносов». 3 нче фильм. 2 һәм 3 серияләр.
18.00 Безнең бакча.
18.30 Меридиан.
18.45 Дөнья яңалыклары иҗаты.
19.15 «ВиД» программасы.
19.30 Мультфильм: «Көтелмәгән вакыйгалар планетасы».
19.40 Җыр турында хатирәләр.
20.10 Нәфис фильм: «Чит кеше алтыны». 4 серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВиД» программасы... Тәнәфестә (00.00)— Телевизион яңалыклар хезмәте.
01.00 «Рикки Повери» эстрада төркеме (Италия).

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильмнар.
8.40 Инглиз теле. 1 уку елы.
9.10 Документаль фильм: «Дингездә сынау».
9.40 Инглиз теле. 2 уку елы.
10.10 Балалар өчен фильм: «Дүрт дусның тормышы һәм маҗаралары».
12.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
12.25 Төркестан хәрби округының җыр һәм бию ансамбле концерты.
12.45 Фильм-спектакль: «Өйдәге үзагым».
13.40 Документаль фильм премьерасы: «Танго».
13.50 Ф. Красиловский җырлый.
14.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
21.45 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
23.45 Нәфис телефильм: «Фән корбаны».

Кычытканлы авылында яшәүче кадерле әтиебез Вакыйф Ярулла улы һәм әниебез Рәйсә Сәгыйть кызы Яруллиннарны 65 яшь һәм бергә тормыш итүләренә 40 ел тулу уңае белән чын күңелдән котлыйбыз, күп елларга нык сәламәтлек, озын гомер, бәхет, тигезлек телибез.

БАЛАЛАРЫ.

Авылым моңнары кире кайта

Киекле авылы культура йортын Казан, Әлмәт, Минзәлә һәм башка шәһәр артистлары читләтеп үтми. Концерт һәм спектакльләр еш булып тора. Сәнгать яратучы Киекле һәм Үрнәк халкы бу тамашаларга бик теләп йөри.

Менә моңа соңгы вакытта күрсәтелгән концерт та шаһит. Биредә авылыбызның төрле яштәге үзешчән артистлары катнашкан иде: мәктәп укучылары да, өлкән яштәгеләр дә. Җырчы Насыйх Газизов, баянчы Сәлих Фәссахов, гармунчы Вәгыйзь Газизов, җырчы һәм биюче Минхәер Мөгайнетдинов, җырчы һәм нәфис сүз остасы Вәли Әхмәтҗанов, укучылар ансамбле, Нурания Хәйретдинова һәм башкалар үзләренең осталыкларын, сәләтләрен күрсәттеләр.

Өч сәгатькә сузылган бу тамашадан берәү дә туймады, шыгырым тулы зал алкышлар белән күзәтте.

Колхоз ансамбленең республика күләмендә шаулаган чаклары да бар иде. Композиторлардан Ифрат Хисамов, Сара Садыйкова, авылдашларыбыз В. Әхмәтҗанов, В. Гафуров сүзләренә Киеклегә багышлап җырлар да иҗат иттеләр.

Хәер, авылда да, тирә-якта да спектакль, концертлар куелып килде үзе. Әммә аңа җитәрлек игътибар бирелмәде генә.

Халыкның таралуы, бигрәк тә башлап йөрүчеләрнең читкә китүе сәбәпле җыр культура йортында сүнә язган иде, ләкин талантлар бар икән әле. Минемчә, колхоз идарәсенә дә, авыл Советына да бу эшне җанландырасы бар. Авылым моңнары кире кайтсын.

Н. ГАТАУЛЛИН.

БЕЛДЕРҮЛӘР

Нурлат-Октябрь таралар ремонтлау участогына ремонтчылар кирәк. Хезмәткә түләү аена 180—250 сум.

Столярлар, мебельчеләр кирәк. Җитештерелгән продукциянең гомуми суммасыннан 30 проценты аларга түләнә.

x x x

Октябрь район Советы башкарма комитетының күптармаклы производство предприятиесе шәһәр мунчасының билет бәясе 63 тиенгә күтәрелүен хәбәр итә.

АДМИНИСТРАЦИЯ.

Октябрь районы халык мәгариф бүлеге һәм профсоюз комитетлары рәисләре советы РОНО инспекторы Р. Х. Фәйзуллинаның әнисе

ГАСИМӘ ВӘЛИ кызы ГАЗАЛИЕВАның

вафат булуы сәбәпле аның тирән кайгысын уртаклаша.

Октябрь район элемтә узелы коллективы төп касса операторы Рәшидә Әхәт кызы Летфуллинаның әнисе

ӘНҮЗӘ САДЫЙК кызының

үлүе сәбәпле аның тирән кайгысын уртаклаша.

РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Нурлат-Октябрь типографиясе.

Күләме—1 басма табак. Заказ 35. Тираж 3 350.